РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_12_» __ноябрь_ 2024 ел №_273__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге өченче затлар хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Чирмешән муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге өченче затлар хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы карарына (район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 252 номерлы, 2019 елның 13

декабрендәге 260 номерлы, 2020 елның 13 мартындагы 272 номерлы карарлары белән кабул ителгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарга кушымта нигезендә күчемсез милек объектларын исемлектән төшереп калдырырга.

2. «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2024 елның
12 ноябрендәге 273 номерлы
карары белән
РАСЛАНДЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы карары белән (район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 252 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 260 номерлы, 2020 елның 13 мартындагы 272 номерлы карарлары белән кабул ителгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегеннән төшереп калдырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге

| № п/п | Мөлкәт исеме | Мөлкәтнең урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Башлангыч мәктәп бинасы | ТР, Чирмешән районы, Якты Тау авылы | 168,0 |
| 2 | Мәктәп бинасы | ТР, Чирмешән районы, Урманасты Үтәмеш ав., Совет ур., 34а йорты. | 971,60 |
| 3 | Бүлмә | ТР, Чирмешән районы, Чирмешән ав., Беренче Май ур., 27 й., 10 нчы бүлмә | 15,5 |
| 4 | Бүлмә | ТР, Чирмешән районы, Чирмешән ав., М. Титов ур., 22А йорты, 15 нче бүлмә | 23,8 |
| 5 | Торак пунктларның җирләре | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Иске Үтәмеш авыл җирлеге, Урманасты Үтәмеш авылы, Совет ур., 34а йорты | 4051 |

Район мөлкәт һәм җир
мөнәсәбәтләре палатасы
рәисе урынбасары Гераева Н.М